Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“27”октябрь 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 августындагы 70 номерлы "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 августындагы 70 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында " карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә тубэндэге үзгәрешләр кертү:

13 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференцияләренең аерым вәкаләтләренә керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга..

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Казиле
авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Иске Казиле
авыл җирлеге Советы рәисе И.Х.Сагьдиев